«Раслыйм»
«Сэлэт» ТРЯИФ
Генераль директоры
_____________ Җ.Ш. Сөләйманов
«____»_____________ 2016 ел

**Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның 130-еллык юбилеена багышланган республикакүләм нәфис сүз осталыгы ярышын үткәрү**

**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## 1. Ярышны оештыручылар

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның 130-еллык юбилеена багышланган республикакүләм нәфис сүз осталыгы ярышы (алга таба – Ярыш) «Таттелеком» акционерлык җәмгыяте белән берлектә Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы «Сэлэт» яшьләр иҗтимагый фонды, «Сэлэт» яшьләр үзәге тарафынан оештырыла.

## 2. Ярышның максатлары

Ярыш үз алдына түбәндәге максатларны куя һәм тормышка ашыра:
– әдәбият өлкәсендә сәләтле булган балаларны һәм яшьләрне барлау, аларга иҗади яктан үсүдә ярдәм күрсәтү;
– балаларда һәм яшьләрдә эстетик зәвыкъ һәм әдәби мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләү;
– балаларның һәм яшьләрнең игътибарын татар әдәбиятына һәм татар халкының рухи мирасына юнәлдерү;
– татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайны искә алу;
– сәләтле яшьләрне «Сәләт» оешмасының проектларына чакыру.

## 3. Ярышның катнашучылары

3.1 Ярышта 7 яшьтән алып 22 яшькә кадәр сәләтле мәктәп балалары һәм белем бирү оешмалары студентлары катнаша ала.

3.2 Ярыш түбәндәге яшь категорияләре буенча үткәрелә:

– 7-10 яшь;

– 11-14 яшь;

– 15-17 яшь;

– 18-22 яшь.

**4. Ярышның казыйлар шурасы**

Ярышның казыйлар шурасына Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары, танылган шагыйрьләр һәм прозаиклар, күренекле журналистлар һәм мәдәният эшлеклеләре керә.

**5. Ярышта катнашучыларның эшләренә карата куелган шартлар**

5.1 Ярышта катнашу өчен гаризалар «Сәләт» оешмасының рәсми сайтында www.selet.biz кабул итеп алына.

5.2 Гаризаны тутыру дәверендә урнаштырылган форманың һәр пунктын җентекләп тутыру зарур.

5.3 Ярышта катнашу өчен сайланган әсәр Г.Тукай әсәре булырга тиеш.

5.4 Ярышта катнашу өчен әзерләнгән чыгыш 5 минуттан артмаска тиеш. Казыйлар шурасы чыгыш барышында катнашучыны туктатырга хаклы.

5.5 Чыгыш ясаганда реквизит кулланырга мөмкин.

5.6 Чыгыш татар телендә булырга тиеш.

**6. Ярышның үткәрелү вакыты һәм үткәрелү**

6.1 Ярыш өч этапта үткәрелә:

– 1 этап – 25 март 2016 ел – 17 апрель 2016 ел – читтән торып гаризаларны кабул итү һәм портфолиоларны техник яктан тикшерү этабы;

– 2 этап – 20 апрель 2016 ел – сайлап алынган катнашучыларның казыйлар шурасы алдында чыгыш ясавы;

– 3 этап – тантаналы рәвештә җиңүчеләрне бүләкләү. Үткәрелү вакыты һәм урыны алдан хәбәр ителәчәк.

6.2 Салап алу этабын үткән катнашучылар ярышка чакырыла. Ярыш Казан шәһәрендә «Сәләт» йортында (Островский ур., 23-нче йорт) үткәрелә.

6.3 Тантаналы рәвештә җиңүчеләрне бүләкләү көне һәм вакыты алдан хәбәр ителәчәк.

**7. Ярышны оештыру комитетының контактлары**

Ярышны оештыру комитеты «Сәләт» йортында (Казан, Островский ур., 23-нче йорт) урнашкан. Белешмәләр өчен телефон: 8-939-730-41-34. «Сәләт» оешмасының рәсми сайты: www.selet.biz. «Вконтакте» социаль челтәрендә «Сәләт» оешмасының рәсми төркеме: http://vk.com/selet_official